Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе



Гайсаров Гали 1918 нче елның 4 нче ноябрендә Питрәч районы Шәле авылында 6 нчы бала булып ярлы гаиләдә дөньяга килә. Җидееллык мәктәп, көтүче малай, Казандагы Укытучылар институты, Шәле мәктәбендә укытучы – сугышка кадәр тормышы менә шулар.

1939 нчы елның декабрь аенда Кызыл Армия сафларынаалына. Аны башта Сталинград шәһәрендәге хәрби-сәяси училищега җибәрәләр. Ләкин бу мәктәптә аларга белем алу насыйп булмый. 1940 нчы елның июнь аенда ул Чернигов шәһәрендәге артиллерия полкында хезмәт итә башлый. Сугыш башланганда, Харьков шәһәрендә урнашкан 50 нче танк дивизиясенең 50 нче артиллерия полкында, кече командир булса да, офицерлар җитмәү сәбәпле, взвод командиры вазифаларын башкара.



Харьков, Киев, Белоруссия, Брянск, Смоленск, Орел, Мәскәү, Тула, Чапаевск, Дон елгасы буе, Харьков, Донецк ,Сталино, Украина, Польша, Лодзь, Познань, Варшава, Николаев,Одесса,Тирас-поль,Германия,Берлин.

1942 елның июнь аенда аларның дивизиясе М.Н.Шолоховның Ватаны булган Вышенская станицасы каршысына,Дон елгасы буена килеп, 40 км озынлыкта оборонага урнаша. Декабрь урталарында Донны кичеп чыгып һөҗүмгә күчә.Ике атна эчендә румыннарның 8 армиясе гаскәрләрен тар – мар итә.Шул батырлыклары өчен дивизияләренә "гвардейская" исеме бирелә. Украина,Белоруссия,Польша җирләрен азат итүдәге авыр сугышларда катнашып,2 мәртәбә җиңел,бер мәртәбә авыр җәрәхәт һәм контузия алып,Германия җиренә барып җитә. Берлин өчен барган каты сугышларда катнаша,тагы ике мәртәбә яралана. Гайсаров Гали 1945 елның 1 маенда Берлин өчен барган сугышта катнаша.





Җиңү көнен 1945 елның маенда Берлинда каршы ала. " Сугыш бетәсен һәм җиңүебезне алдан сизә идек, шулай да бу көнне ничек көткәнне белмисез?! Беркайчанда йөрәкләрдән суырылмас минутлар",- диеп искә алды ул. Сугыш беткәч тә әле туган ягына кайтырга туры килми. 1946 елның август аена кадәр Совет Армиясе составында Германиядә хезмәт итә. Бары 1946 елның сентябрендә генә аңа туган төбәге- Шәле авылына кайту насыйп була. "Тынычлыкның кадерен белегез.Безнең кебек сугыш афәтләре күрмәгез.Күкләрегез аяз,илләр имин булсын!" –дия иде ветеран,тормышны ярата иде ул.



Шаһвалиев Йосыф Хәсән улы





Орден, медальләр
Бөек Җиңүнен 60 еллыгы





Солдат хатлары




Мухамадияров Җәвид
С.Ф.Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе




Гибашова Нурия
С.Ф.Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе




Галиуллина Лилия
С.Ф.Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе

Буын арты буын алмашыр, ләкин Бөек Җиңү һәм шушы җиңүне яулап алган какшамас фронт һәм тыл каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр. Хөрмәт сугыш һәм тыл ветераннары! Сезне чын күңелдән Бөек Җиңүнең 70 еллыгы белән котлыйбыз. Сезгә саулык-сәламәтлек, иминлек, тыныч тормыш телибез.Күпме еллар үтсә дә, безнең хәтердә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр. Җиңү бәйрәменә багышланган бәйрәмдә сезнең чал чәчләрегездән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә! Илләребез имин, күкләребез һәрчак аяз булсын!.. Кабат сугыш афәтләрен күрергә язмасын!


**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## “Бер солдат тарихы”

**Гайсаров Гали Сафа улы**



**Сугышчан юлы**





Боевая характеристика
На гв. мл. л-та командира огневого
вз-да Гайсарова
Тов. Гайсаров в подразделении
наш один из лучших офицеров,
много тов. Гайсаров уделяет
внимание на воспитание своих
подчиненных, а также повседневно
повышает свой боевой и политический
уровень знаний. На счету его
вз-да числится уничтожение 75 мм
арт батареи, 105 мм орудие,
подавлено 5 пулеметных точек из них
2 станковых пулемета уничтожено.
Рассеяно и частично уничтожено
до роты пехоты пр-ка
Тов. Гайсаров достоин быть
в рядах большевистской партии
Ко-р 1 бат. 26. гв. с.п.
23/VIII-1944 г.



Гайсаров Гали Сафа улы 1918 нче елның 4 нче ноябрендә Питрәч районы Шәле авылында 6 нчы бала булып ярлы бер гаиләдә дөньяга килә.Җидееллык мәктәп, көтүче малай, Казандагы Укытучылар институты, Шәле мәктәбендә укытучы – сугышка кадәр тормышы менә шулар. 1939 нчы елның декабрь аенда Кызыл Армия сафларына алына.

Аны башта Сталинград шәһәрендәге хәрби-сәяси училищега җибәрәләр. Ләкин бу мәктәптә аларга белем алу насыйп булмый. 1940 нчы елның июнь аенда ул Чернигов шәһәрендәге артиллерия полкында хезмәт итә башлый. Сугыш башланганда Харьков шәһәрендә урнашкан 50нче танк дивизиясенең 50 нче артиллерия полкында,кече командир булса да, офицерлар җитмәү сәбәпле, взвод командиры вазифаларын башкара.

Сугыш башланасы көнне полкның яшь солдатлары хәрби ант кабул итәргә тиеш була. Иртәнге аштан соң хәрби мәйданчыкта олы бәйрәмгә зур командирларның килүен көтәләр.Байтак вакыт үтә.Ант кабул итү һаман

башланмаган. Сәгать 10. Полк дежурные мәйданчыктагы радиоалгыч янына җыелырга приказ бирә. Нинди хәбәр булыр дип,түземсезлек белән көтәләр. Менә көндезге 12 нче яртыларда : “Тыңлагыз, тыңлагыз! Бик мөһим тапшыру булачак!”- дигәч тә, алар сугыш башланганын аңлап алалар. Шул вакыт СССРның Тышкы эшләр министры В.М.Молотовның Совет Хөкүмәте исеменнән бөтен совет халкына мөрәҗәгате яңгырый.Митингтан соң дошманга каршы фронтка китү өчен хәзерлек башлана. Төнлә белән аларны, эшелоннарга төяп, фронтка озаталар. Полклары авыр артиллерия булып саналса да,бары 8 авыр гаубица гына була.Беллоруссиянең Буда Кошелевская станциясеннән пушкалар алып кайту өчен,фронтның алгы сызыгына дүртәр мәртәбә командировкага баралар. Дошманның бертуктаусыз дәвам иткән һава һөҗүме астында, көнгә 3-4 рейс ясап,үз полкларына пушкалар алып кайта.Аларның танк дивизиясен кайда авыр участок, шунда җибәрәләр.Ләкин 1941 елның 17 августында дивизия Гомель өлкәсендә чолганышта кала. Алар, сугыша –сугыша, Брянск өлкәсенең Уныч шәһәренә килеп җитәләр. Аны азат итсәләр дә,дошман көчлерәк булып чыга. Бер кечкенә генә урман эчендә чолганышта калалар. Менә шул көннән Гали абый һәм 10 солдат өчен авыр көннәр башлана. Урман эчендә чыршы төбендә 5 көн авызга бер тамчы ризык капмыйча,эт өргән һәм ату тавышлары тынгач,төрле азык җыеп туклана алар.10 көннән соң бу урманнан чыгып, Көнчыгышка(Мәскәүгә) таба юл тоталар. Авылларда немецлар булганлыктан,читләтеп үтәләр. Ач та, ялангач та була алар, хәер дә соранып йөрергә туры килә. Шулай Брянск, Орел, Смоленск, Калуга, Тула өлкәләренең бик күп авыллары,шәһәрләре аша үтеп, 1941 елның 19 декабрендә Тула өлкәсенең бер авылында Совет Армиясе солдатлары белән очраша.Тагы авырлыклар... И.В.Сталин боерыгы нигезендә, дошман басып алган җирдә булган дип, НКВДы тикшерүе үтәләр. Каты тикшерү үткәч,Куйбышев өлкәсенең Чапаевск шәһәрендә яңа оешкан дивизия карамагына җибәрәләр. 1942 елның июнь аенда аларның дивизиясе М.Н.Шолоховның Ватаны булган Вышенская станицасы каршысына, Дон елгасы буена килеп, 40 км озынлыкта оборонага урнаша. Декабрь урталарында Донны кичеп чыгып һөҗүмгә күчә.Ике атна эчендә румыннарның 8 армиясе гаскәрләрен тар – мар итә.Шул батырлыклары өчен

дивизияләренә “гвардейская” исеме бирелә.Шушы дивизиянең 128 гв.артполкы составында, Украин җирләрен азат итә -итә, Изюм шәһәренә килеп җитәләр. Март аенда Гайсаров Гали абыйны полк штабына чакырып алалар һәм 1 гв. Армиясенең кече лейтенантлар хәзерли торган курсына укырга җибәрәләр.Укуны тәмамлагач,яңадан 57гв. Дивизиясенең 128 гв.артполкында гвардия кече лейтенанты взвод командиры буларак, Украина, Белоруссия, Польша җирләрен азат итүдәге авыр сугышларда катнашып, 2 мәртәбә җиңел, бер мәртәбә авыр җәрәхәт һәм контузия алып, Германия җиренә барып җитә. 1945 елның 1 маенда Берлин өчен барган каты сугышларда катнаша,тагы ике мәртәбә яралана.

Сугыш беткәч тә әле Гали абыйга туган ягына кайтырга туры килми. 1946 елның август аена кадәр Совет Армиясе составында Германиядә хезмәт итә.

Бары 1946 елның сентябрендә генә аңа туган төбәге- Шәле авылына кайту насыйп була. Кайтуга яраткан эше – укытучылык хезмәтенә керешә. 1983 елга кадәр туган мәктәбендә балаларга рус теле һәм әдәбияты укыта. Шул вакытта җәмәгать эшләрендә актив катнаша, пропагандист вазифаларынбашкара. Тырыш хезмәтләре өчен Дәүләтебезнең бик күп Грамоталарына һәм Мактау кәгазьләренә лаек була.

1951 нче елда Зәйтүнә белән гаилә корып җибәрәләр. Бер кыз һәм өч малай үстерәләр, һәркайсына югары белем бирәләр.

**Гайсаров Гали Сафа улының алган бүләкләре**


Тов. гв. Лейтенанту Гайсарову Гали Сафичу

Приказом Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза товарища Сталина от 2 мая 1945 г. № 359 за взятие Берлина всему личному составу нашего соединения, в том числе и Вам, принимавшему участие в боях, ОБЪЯВЛЕНА БЛАГОДАРНОСТЬ.

КОМАНДИР ЧАСТИ (подпись)

Мы в битвах решаем судьбу поколений,
Мы к славе отчизну свою поведем!







Гайсаров Гали абыйның безгә сөйләр сүзләре күп иде. Безгә һәрчак: “Тынычлыкның кадерен белегез. Безнең кебек сугыш афәтләре күрмәгез. Күкләрегез аяз, илләр имин булсын!” –дия иде.Тормышны ярата иде ул. “Әле Җиңүнең 65 еллыгын да күрәм”,- дип өметләнә иде. Мәктәп укучыларының яраткан кунагы иде. Очрашуларга бик теләп бара, үзенең башыннан үткәннәрне мавыктыргыч итеп сөйли иде. Авылдашларыбыз да аны хөрмәт итә, олылый иделәр. Соңгы юлга озатырга да авыл халкы гына түгел, районнан да бик күп кеше килде.  Аның киңәшләре безгә һәрчак маяк, әйткән сүзләре тормышыбыз девизы булып тора. Без аны беркайчан да онытмабыз.





**Гайсаров Гали абый мәктәп укучыларының еш кунагы иде.**

# Бөек Җиңү турында истәлекләре.

*Бөек Җиңүнең 53 еллыгына*

## Безнең яшьлек шулай үтте



Немец-фашист илбасарлары безнең Илебезгә юлбасарларча басып кергәч, сөекле Ватаныбызны саклау өчен безнең Шәле авылыннан 481 ир-егет сугыш кырына китә. 268 кеше мәңгегә ятып кала. Бары 213 кеше генә туган авылына кайта. 104 ана якын балаларыннан аерыла, хатын-кыз тол кала.

Еллар үтә. Хәзерге көндә авылыбызда бары 26 гына сугыш ветераны, ирләрен фронтта югалтып тол хатыннардан бары 31 генә карчык исән.

Ә сугыш елларында фидакарь хезмәтләре өчен 214 хатын-кыз дәүләтебезнең орден-медальләре белән бүләкләнгән иде.

Мин үзем Совет Армиясе сафларына совет-фин сугышы көннәрендә, 1939 елның декабрь аенда алындым. Безне, районыбызның иң алдынгы, зур булмаган җитәкче оешмаларда эшләүче 6 коммунистны, Сталинградның хәрби-сәяси мәктәбенә укырга җибәрделәр.

Ләкин бу хәрби мәктәптә безгә сугыш белеме алу насыйп булмады.

Бөек Ватан сугышы башланганда, мин Харьков шәһәрендә урнашкан 50 нче танк дивизиясенең 50 нче артиллерия полкында кече командир булсам да, офицерлар җитешмәү сәбәпле, взвод командиры вазифасын башкара идем.

Ватан сугышы башланган көнне безнең полкның яшь солдатлары хәрби ант кабул итәргә тиешләр иде.

Иртәнге аштан соң без хәрби шәһәрчек мәйданына җыйналып, олы командирларыбызның килүен көтәбез. Байтак вакыт үтте. Ант кабул итү һаман башланмый. Менә көндезге сәгать уннар тирәсендә полк дежурные безнең янга килеп: "Хәрби ант кабул итү кичектерелеп тора. Хәзер үзегезнең солдатларыгыз белән хәрби мәйдандагы радиоалгыч янына килегез", — дип китте. Безнең өскә кайнар су сипкәндәй булды. Хәрби ант кабул итү армия тормышында иң зур тантана. Кинәт ул кичектерелә.

Без радиоалгычтан нинди хәбәр әйтерләр икән дип, түземсезлек белән көтәбез.

Менә көндезге сәгать уникенче яртыларда: "Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бик мөһим тапшыру булачак!" – дигәч, без, чыннан да, сугыш башланган икәнен аңлап алган идек инде.

СССРның Тышкы эшләр министры В.М.Молотовның Совет Хөкүмәте исеменнән бөтен халыкка мөрәҗәгате яңгырады. Шушыннан соң безнең полкта кыскача митинг уздырылды. Чын-чынлап дошманга каршы фронтка китү өчен хәзерлек башланды. Төнлә безне эшелоннарга төяп фронтка озаттылар.

Безнең полк авыр артиллерия полкы саналса да, бары 8 авыр гаубица бар иде. Белоруссиянең Буда Кошелевская станциясеннән пушкалар алып кайту өчен, фронтның алгы сызыгыннан 4 мәртәбә командировкага җибәрделәр. Дошманның бертуктаусыз дәвам иткән һава һөҗүме астында, көнгә 3-4 рейс ясап, үзебезнең полкка авыр пушкалар алып кайттым. (Безнең авыр пушкаларны (152 мм лы) 1930 елларда заводтан чыгып колхоз-совхоз кырларында таушалып беткән ЧТЗ тракторлары тарта иде).

Безнең танк дивизиясен кайда авыр участок – шунда күчереп тордылар. Дивизия дошманның һөҗүмен туктатып, үзе һөҗүмгә күчә иде. Ләкин алга таба бару шатлыклары озакка бармады: 1941 елның 17 августында безнең дивизия Гомель өлкәсендә чолганышка эләкте. Без сугыша-сугыша Брянск өлкәсенең Уныч шәһәренә килеп җитеп, аны азат итсәк тә, дошманның көче өстенрәк булып чыкты. Байтак кына техника һәм солдат бер кечкенә генә урман эчендә чолганышта калды.

И.В.Сталинның 1941 ел 3 июльдәге радио аша халыкка мөрәҗәгатендә куелган бурычлар нигезендә, пушканы һәм тракторны яраксыз хәлгә китергәннән соң, кем ничек котыла ала, шулай итеп төрле якка таралдык. Шушы урман эчендә чыршы төбендә 5 көн дәвамында авызга бернәрсә капмый ятканнан соң, эт өргән һәм атышу тавышлары ишетелми башлагач, төрле азыклар җыеп туклandык. 10 көннән соң бу урманнан чыгып Көнчыгышка (Мәскәүгә) таба юл тоттык. Ләкин авылларда немец гарнизоннары булганлыктан, читләтеп үтә идек. Бер ай чамасы совет солдаты киемендә качып-посып йөргәннән соң, солдат формасын бер авылда иң әшәке киемсалымга алыштырырга туры килде. Немец солдат киемендә күрсә, шунда ук атып үтерә иде. 1941 елның 19 августыннан 19 декабренә кадәр мин хәер сораныл Брянск, Орел, Смоленск, Калуга һәм Тула өлкәләренең бик күп авылларын үттем. Ашарга-эчәргә бирмиләр, кунарга кертмиләр. Бәхеткә 1941 елның 19 декабре көнне Тула өлкәсенең бер авылында Совет Армиясе солдатлары белән очраштым.

И.В.Сталин боерыгы нигезендә безне хәрәкәттәге армия сафына алмадылар, ә әсирлектә булган, дошман басып алган җирдә булучылар НКВД тикшерүен үтәргә тиеш булды. Каты тикшерү үткәч, Куйбышев өлкәсенең Чапаевск шәһәрендә яңа оешма торган дивизия карамагына җибәрделәр.

1942 елның июнь аенда безнең дивизия М.Н.Шолохов ватаны булган, Вышенская станицасы каршысына, Дон елгасы буена килеп 40 км озынлыкта оборонага урнашты. Безнең дивизия 1942 елның декабрь ае урталарына кадәр шушы районда оборонада торганнан соң Дон елгасын кичеп чыгып һөҗүмгә күчте. Ике атна эчендә румыннарның 8 армиясе гаскәрләрен тар-мар итте. Безнең дивизиягә "гвардейская" исеме бирелде. Шушы дивизиянең 128 гв. артполкы составында Украина җирләрен азат итә-итә без Изюм шәһәренә килеп җиттек. Март ае ахырлары булса кирәк, мине полк штабына чакырталар һәм 1 гв. Армиясенең кече лейтенантлар курсына укырга җибәрәләр. Бу курсларны июнь аенда бетереп чыкканнан соң, безне запастагы полкка җибәрәләр. Шушы полкта мин элек Питрәч РОНО мөдире булып эшләгән капитан Таһиров Шәйхетдин абый белән очраштым.

Бу полкта булуымның икенче көнендә Шәйхетдин абый миңа: "Гали, әле хәзер генә безгә И.В.Сталинның приказын укыдылар. Бу приказ нигезендә әсирлектә, яки оккупацияләнгән территориядә булучылар махсус тикшерү "үтәргә тиешләр" диде.

Мин яңадан 57 гв. дивизиясенең 128 гв. артиллерия полкы составында гвардия кече лейтенанты взвод командиры буларак Украина, Молдовия, Белоруссия, Польша җирләрен азат итүдәге авыр сугышларда катнашып, 2 мәртәбә җиңел, бер мәртәбә авыр җәрәхәт һәм контузия алып Германия җиренә барып җиттек.

Берлин өчен барган каты сугышларда катнашып, тагы 2 мәртәбә җиңел яраландым. 1946 елның август аена кадәр Совет Армиясе составында Германиядә хезмәт иттем.

Туган авылыма кайткач, тагы укытучы булып эшли башладым һәм 1981 елда лаеклы ялга чыктым.

**Гали Гайсаров,**
II группа сугыш инвалиды, хезмәт һәм сугыш ветераны.

*Рәсемдә:* Гали Гайсаровның яшь вакыты. 1946 ел, 31 август, Веймар шәһәре, Бухенвальд.

**“Туган акны өйрәнү музеенда” бер солдат тарихы.**







**Шаһвәлиев Йосыф Хәсән улы**

Орден – медальләре

1926 нчы елда Йосыф абый әти-әнисенә сөенеч булып дөньяга килә.

1936 нчы елда әтисе репрессия корбаны була. Халык дошманы диеп, мал-мөлкәтләрен, өйләрен тартып, кулга алалар. Бу вакытта Йосыф абыйга 10 яшь кенә була. Торырга урын булмаганлыктан, ун ел буе ат сараенда яшәргә туры килә аларга. Ата назына сузаган бала түзә, сыгылмый. Инде 12 яшьтән үк колхозга эшкә чыга. 9 елдан соң зарыгып көткән, кадерле әтиләре кайта. Ләкин шулай язгандыр инде күп гомер бирми аңа Ходай: берничә елдан , әтисе хәзер инде гомерлеккә, гаиләсе белән хушлаша. 1944 нче елның язында армиягә алына. Сугышның иң дәһшәтле вакытына эләгә. Белоруссия, Украина, Польшада Ватан каршындагы бурычын үти. Мастер авиоружения булып хезмәт итә. 22 пулемет, бомбалар озатып калалар. Үзләренең командирларын һәрвакыт искә ала Йосыф абый: “ Михайлов- советлар союзы герое”. Берлинга 100 чакрым кала, җиңү көнен каршы алалар. “ Сугыш бетәсен һәм җиңүебезне алдан сизә идек, шулайда бу көнне ничек көткәнне белмисез?! Беркайчанда йөрәклэрдән суырылмас минутлар”,- диеп искә алды ул. Германияне җиңгәннән соң, Япония белән сугыш башланып китә. Бу сугышларда да катнашырга туры килә. Сөенечкәдер инде әлеге сугыш озакка сузылмый, безнең якта- җиңү!

1944 нче елдан алып 1951 нче елга кадәр армия сафларында хезмәт итә. Барлыгы җиде ел, бу күпләргә үрнәк. Әле ул гына да түгел, 1952 нче елда тагын повестка килә. 3 ай тагын армиядә булып кайта. Хәзерге көн белән Йосыф абый канәгать, әледән әле Нәгыймә апа белән иңгә иң куеп, балаларына, онык-оныкчыкларына сөенеп, куанып яшәп килә бирәләр. Аларга карап сокланып куясың, бар яктан да алар киләчәк буенга үрнәк! “ Балаларыбыз да, хөкүмәт тә бар яктан да булышып тора. Туасы көннәребез аяз, тыныч имин булсын иде. Без күргәннәрне киләчәк буынга күрергә язмасын”,- диеп теләде Йосыф абый.



**Солдат хатлары.**

**“Балалар Җиңүне сурәтли”.**

С.Ф.Әхмәтҗанович исемендәге
Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары иҗаты



Мухамадияров Җәвид.



Гибашова Нурия.



Галиуллина Лилия.

**Ветераннарга рәхмәт сүзләре.**

Сугыш... Күпме сагыш, кайгы, күз яшьләре алып килдең син! Никадәр югалту, бәхетсезлек китердең тынычлык халкына. Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың. Безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек , курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән аналары бар. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән Җиңү таңын каршылады. Әйе, Җиңү исәпсез-хисапсыз корбаннар барәбәренә яуланды. 70 нче Җиңү язын каршыларга җыенабыз. Тагы күп дистә еллар үтәр. Буын арты буын алмашыр, ләкин Бөек Җиңү һәм шушы җиңүне яулап алган какшамас фронт һәм тыл каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр.

Хөрмәт сугыш һәм тыл ветераннары! Сезне чын күңелдән Бөек Җиңүнең 70 еллыгы белән котлыйбыз. Сезгә саулык-сәламәтлек, иминлек, тыныч тормыш телибез.

Күпме еллар үтсә дә, безнең хәтердә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр. Җиңү бәйрәменә багышланган бәйрәмдә сезнең чал чәчләрегездән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән

юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә!  Илләребез имин, күкләребез һәрчак аяз булсын!.. Кабат сугыш афәтләрен күрергә язмасын!..

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль  районы  Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗанович исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе

**«Не померкнет летопись Победы»**

Эшләде: 8 б сыйныф укучысы Шәмсиева Динәрә

Җитәкчесе: Мухутдинова Рәсилә Мәгъсүм кызы, I категорияле тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы.